Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Уракчы ав. 15 нче февраль 2016 ел

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 26 декабрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү сәбәпле, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлешләре, «Уракчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Уракчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 26 декабрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36а йорты; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Гәрәев